**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

«23» ноябрь 2023 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүгә;
- Тукай п. чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;
- Тукай п. территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев